# ШАРТАН

**Чуаш халкы милли ризыгы шартан пешерәбез:**
Бу – чуашларның иң танылган ит ризыгы. Элек тә, хәзер дә яратып ясала һәм ашала торган сый. Озак әзерләнә торган ризык. Үзенә күрә колбасаны да хәтерләтә. Әмма күпкә тәмлерәк, хуш ислерәк була дип ышандыралар чуашлар.

Авылның хөрмәтле кешесе Вера Леонтьевна безгә әлеге ит сыен ничек дөрес әзерләргә кирәклеген аңлатты:

– Бәрән суйгач, аның итен сөякләрдән аерасы. Бәрәннең ашказаны, ите кирәк. Тәменчә тоз-борыч, төрле тәмләткечләр кулланырга була. Бәрәннең ашказанын юып, эчен тышка әйләндереп, кабат юасы, чайкыйсы, чистартасы. Итне зур булмаган кисәкләргә турап, тозлап-борычлап, яхшылап болгатасы.  Шушы итне ашказанына тыгыз иттереп тутырасы, җеп белән нык итеп тегәсе. Бер тәүлеккә мичкә тыгасы. Ризык бик туклыклы, кирәк кадәр тозлы да. Тутырмага охшамаган. Итне үзен генә түгел, маен да тутырырга кирәк, алай ризык тәмлерәк тә чыгачак.



Источник: Гарифуллина, Ч. Исәнмесез! Аван-и! / Ч. Гарифуллина // Ватаным Татарстан. – 2022. - № 97(9 июль). – Б. 97. – URL: https://vatantat.ru/2022/07/86804/